**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«05» декабрь, 2025 ел Иштирәк авылы № 12

«Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетның 2023 елның 13 февралендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр керү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 5 өлеше, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетның 2023 елның 13 февралендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне керетергә:

1.1. 3.7, 3.8 пунктларында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 статьяның 2.4 пункты 1 пунктчасында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 статьяның 2.4 пункты 2 пунктчасында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.4. 4 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцмяләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www. pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.П. Васильева